ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 96 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^8$ пункт өстәргә:

«$9^8$) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларына кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә карар кабул итү;»;

2) 10 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы милкенә караган торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары, дини билгеләнештәге мөлкәткә яисә «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә һәм (яисә) 12 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мөлкәткә караган мәдәни мирас объектларыннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы карары белән физик яисә юридик затларга, әлеге статьяда билгеләнгән таләпләр үтәлгәндә, 49 елга кадәр вакытка, ташламалы аренда түләвен билгеләп, арендага тапшырылырга мөмкин.»;

б) 2 өлештә «торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган» сүзләрен «Татарстан Республикасы милкенә караган торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «Торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган» сүзләрен «Татарстан Республикасы милкенә караган торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлештә «Торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган» сүзләрен «Татарстан Республикасы милкенә караган торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 өлештә «Торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган» сүзләрен «Татарстан Республикасы милкенә караган торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган» сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 өлештә «Торышы канәгатьләнерлек булмаган, муниципаль милеккә караган» сүзләрен «Муниципаль милеккә караган торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән аренда шартнамәләренә кагылмый.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 10 апрель
№ 17-ТРЗ